Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге Советының утыз җиденче утырышы

Екатериновка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2018 елның 1 октябре № 81

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы “Җирле референдум турында” законының 18 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пунктына, Екатериновка авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Екатериновка авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендәге 80 номерлы “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” һәм Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитетының “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 14 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган алдагы сорауны расларга: “2019 елда яшәү урыны Екатериновка авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, 18 яшькә җиткән һәр Россия Федерациясе гражданыннан 500 сум үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме:

- Екатериновка авыл җирлеге территориясен төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны “Вперёд” (“Алга”) район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга

(http://pravo.tatarstan.ru), Екатериновка авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Жуков